ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ПОСЕЛКА ГОРОДСКОГО ТИПА УРУССУ
ЮТАЗИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО
РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
423950, п.г.т. Уруссу, ул. Пушкина, 38

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
УРЫССУ ШӘҺӘР ТИБЫНДАГЫПОСЕЛОГЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ
423950, Урыссу шәһәр тибындагы поселогы
Пушкин урамы, 38

Тел.: 8(85593)2-92-40, факс: 2-61-50, e-mail: Pgt.Urussu@tatar.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

« 04 » 02. 2022г. № 5

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитетының 2018 елның 28 маендагы 19 номерлы карары белән расланган «Җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты»на үзгәрешләр кертү турында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы 210-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 2 ноябрендәге «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында»гы 880 санлы карары, Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Советының 2020 елның 28 апрелендәге 5 номерлы карары белән кабул ителгән Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының “Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитеты карар бирә:

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Урыссу шәһәр тибындагы поселогы Башкарма комитетының 2018 елның 28 маендагы 19 номерлы карары белән расланган «Җир кишәрлегеннән шартлы рәвештә рөхсәт ителгән файдалану төрен үзгәртү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламенты»на түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. «Муниципаль хезмәт күрсәтү стандарты» 2 бүлеге 2.14 пунктын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

| | | |
|---|---|---|
| 2.14. Муниципаль хезмәт күрсәтү залына, көтү залына, муниципаль хезмәт күрсәтү турында запросларны тутыру урыннарына, аларны тутыру үрнәкләренә һәм һәр муниципаль хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документлар | Муниципаль хезмәт күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы белән җиһазландырылган биналарда һәм корылмаларда башкарыла.<br>Гариза бирүчеләрне кабул итү урыннары документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, | 2010 елның 27 июлендәге «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында»гы 210-ФЗ санлы Федераль закон; |

| | | |
|---|---|---|
| исемлегенә, мондый хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматларын урнаштыру һәм рәсмиләштерү, шул исәптән федераль законнар һәм инвалидларны социаль яклау турында Татарстан Республикасы законнары нигезендә инвалидлар өчен күрсәтелгән объектларның үтемлелеген тәэмин итүгә карата таләпләр | мәгълүмати стендлар белән җиһазландырыла.<br>Инвалидларның муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алуы тәэмин ителә (бинага керү-чыгу һәм алар чикләрендә күчеп йөрү).<br>Муниципаль хезмәт күрсәтү тәртибе турында визуаль, текст һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып, урнаштырыла.<br>Социаль яклау турында Россия Федерациясе законнары нигезендә, муниципаль хезмәт күрсәтү урынына тоткарлыксыз керә алу максатларында инвалидларны социаль яклау тәэмин ителә:<br>1) күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт функциясе бозылган инвалидларны озатып бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;<br>2) транспорт чарасына утырту һәм аннан төшерү, шул исәптән кресло-коляска кулланып;<br>3) инвалидларның хезмәт күрсәтүләргә, тормыш эшчәнлеге чикләүләрен исәпкә алып, тоткарлыксыз үтеп керүен тәэмин итү өчен кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөртүчеләрне тиешенчә урнаштыру;<br>4) инвалидлар өчен кирәкле тавыш һәм күрү мәгълүматын, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм Брайль рельеф-нокталы шрифты белән башкарылган башка текст һәм график мәгълүматны дубликацияләү;<br>5) сурдотәрҗемәче һәм тифлосурдотәрҗемәче керүгә рөхсәт;<br>6) Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге «Озата баручы этне махсус өйрәтүне раслый торган документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында»гы 386н санлы боерыгы белән билгеләнгән тәртиптә һәм форма | 1995 елның 24 ноябрендәге «Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 181-ФЗ санлы Федераль закон |

| | | |
|---|---|---|
| | буенча бирелә торган документ булган очракта озата баручы этнең керүенә рөхсәт;<br>7) Башкарма комитет хезмәткәрләре тарафыннан инвалидларга, башка затлар белән беррәттән, инвалидларга хезмәт күрсәтүгә комачаулаучы киртәләрне җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү.<br>Инвалидлар өчен муниципаль хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырыла торган объектларга һәм әлеге пунктның 1 - 4 пунктларында күрсәтелгән муниципаль хезмәт күрсәтүдә кулланыла торган акчаларга үтемлелекне тәэмин итү өлешендә 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган яисә модернизация узган объектларга һәм чараларга карата таләпләр кулланыла. | |

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының “Урыссу шәһәр тибындагы поселогы» муниципаль берәмлеге территориясендә махсус мәгълүмат стендларында халыкка җиткерергә, Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге адрес буенча бастырып чыгарырга: http://pravo.tatarstan.ru, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы сайтында Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре «Рәсми Татарстан» порталы составында дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы составында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru адресы буенча урнаштырырга.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен үз җаваплылыгымда калдырам.

Җитәкче вазифаларын башкаручы А.Н. Захаров